Республика Татарстан
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«КАРКАЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»

ул.Советская, д.93, с.Каркали,
Лениногорский район, 423272
Тел./факс: (85595) 3-67-01
E-mail: Kark.Len@tatar.ru

Татарстан Республикасы
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
«КЕРКӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 93 йорт, Керкэле авылы, Лениногорс
районы, 423272
Тел./факс: (85595) 3-67-01
E-mail: Kark.Len@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның 14 мартыннан № 4

«Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 26 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Керкәле авыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре шулай ук, әгәр бу бозып күрсәтелгән мәгълүматлар мөһим булмаса, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы ( 26.01.2023 ел ред.) Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 26 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Керкәле авыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре шулай ук, әгәр бу бозып күрсәтелгән мәгълүматлар мөһим булмаса, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 2 абзацында, 4 пунктында, 5 пунктның 3 абзацында, 6 пунктның 1 абзацында, 7 пунктның 1,3 абзацларында «Президентны» сүзен «Башлыгын - Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның 1 абзацында «Президентка» сүзен «Башлыгына - Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Керкәле авылы, Совет урамы, 93 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл

җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Л.И.Бигманов